МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.09.2019 Казан ш. № 664.

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 20 сентяберендә 5804 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к  б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының халыкка социаль ярдәм өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 3 сентябрендәге 664 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Хезмәткә сәләтне югалту дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә (инвалидлык билгеләнмәсә дә), техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булу сәбәпле һәм хезмәткә сәләтне югалтуга китергән сәламәтлеккә зыянны каплауга айлык акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2013 елның 01 апрелендәге 181 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 25.02.2015 № 103, 05.10.2015 № 702, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 351, 30.11.2017 № 840, 15.05.2018 № 368, 18.09.2018 № 883, 20.06.2019 № 486 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Хезмәткә сәләтне югалту дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә (инвалидлык билгеләнмәсә дә), техноген һәлакәтләр аркасында радиация тәэсиренә дучар булу сәбәпле һәм хезмәткә сәләтне югалтуга китергән сәламәтлеккә зыянны каплауга айлык акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлекнең 1.6 пунктында:

икенче абзацта «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

җиденче абзацта «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктта «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гарызнамә җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча хезмәт алучының хосусый шәхси счетының иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар алына (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган вәкаләтле оешма хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән

язмача рәвештә хәбәр итеlә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

2.12 һәм 2.15 пунктларның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.1 пунктның 3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) компенсация билгеләү буенча документлар җыелмасын кушып, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү;

7) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.3 пунктча өстәргә:

«3.3.3. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.3.3.1. Үзәкнең бүлек белгече хосусый шәхси счетның иминият номеры турында электрон формада мәгълүмат ала (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

3.3.3.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Россия Федерациясе Пенсия фондына хосусый шәхси иминият номеры турында белешмәләр бирү турында үтенечләр җибәрә.

3.3.3.1 һәм 3.3.3.2 пунктчаларда билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында гарызнамәләр.»;

3.4.1 пунктчада:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк белгече әлеге Регламентның 3.3.3 пунктчасында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Документларны ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша сорату зарурлыгы булганда, – гарызнамәләргә җавап килгән


вакыттан башлап ике эш көне эчендә, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиңе эш көненнән соңга калмыйча.»;


4 бүлекнең 4.1 пунктындагы икенче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек)» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техноге́н һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләт югалуга сәбәп булган зыянны каплауга, хезмәткә сәләт югалу дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә (инвалидлык билгеләмичә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Техноген һәлакәтләр нәтиҗәсендә радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән һәм хезмәткә сәләт югалуга сәбәп булган зыянны каплауга, хезмәткә сәләт югалу дәрәҗәсенә бәйсез рәвештә (инвалидлык билгеләмичә) ай саен түләнә торган акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча БЛОК-СХЕМА






2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 602 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 18.11.2015 № 850, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 350, 15.11.2017 № 802, 19.02.2018 № 138, 15.05.2018 № 368, 18.09.2018 № 886, 20.06.2019 № 486 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплау өчен ай

саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктның 3 пунктчасында «РФ ЮС № 2123-1 карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Югары Советының 2123-1 номерлы карары» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта:

икенче абзацта «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче һәм алтынчы абзацларда «РФ законнары» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

унберенче абзацта «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

унөченче абзацта «РФ законнары» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 һәм 2.3 пунктларның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гариза җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң сигез эш көненә кадәр озайтыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге белешмәләрне раслаучы документлар алына:

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);

тукландыручының вафат булуы турында (гражданлык хәле актларын теркәү органнарында);

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан пенсия алу факты турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (Россия Федерациясе эчке эшләр органнарында);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган вәкаләтле оешма хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

2.12 һәм 2.15 пунктларның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

3 нче бүлектә:

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан дәүләт хезмәте алучыга пенсия билгеләү турында;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

тукландыручының вафат булуы турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарыннан;

компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында Россия Федерациясе эчке эшләр органнарыннан;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан – хосусый шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр).

3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне бирү турында үтенечләр җибәрә:

Россия Федерациясе Пенсия фондына – дәүләт хезмәте алучыга пенсия билгеләү турында;

балалар тууны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

гаилә коруны дәүләт теркәвенә алу турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

тукландыручының вафат булуы турында гражданлык хәле актларын теркәү органнарына;

компенсация алучының яшәгән урыны буенча теркәлгән гражданнар турында Россия Федерациясе эчке эшләр органнарына;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында гарызнамәләр.»;

3.5 пунктның 3.5.1 пунктчасында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк белгече әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Документларны ведомствоара хезмәттәшлек

каналлары аша сорату зарурлыгы булганда, – гарызнамәләргә җавап килгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң биш эш көненнән соңга калмыйча.»;


4 бүлекнең 4.1 пунктындагы икенче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек)» сүзләрен төшереп калдырырга;


Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплауга ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Радиация тәэсиренә бәйле рәвештә сәламәтлеккә китерелгән зыянны каплауга ай саен түләнә торган акчалата компенсация (сумма) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча

БЛОК-СХЕМА






3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлану нәтиҗәсендә радиоактив пычранган аерым зоналар территориясеннән яңа яшәү урынына эвакуацияләнгән һәм күчерелгән (күчерелүче), шулай ук ирекле рәвештә чыгып киткән гражданнарга яңа һөнәрләргә өйрәнү һәм эшкә урнашу чорына уртача хезмәт хакын саклау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 26 июлендәге 601 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 26.10.2015 № 762, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 350, 30.11.2017 № 841, 15.05.2018 № 368, 18.09.2018 № 883, 20.06.2019 № 486 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Чернобыль АЭСындагы һәлакәт, 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар ташлану нәтиҗәсендә радиоактив пычранган аерым зоналар территориясеннән яңа яшәү урынына эвакуацияләнгән һәм күчерелгән (күчерелүче), шулай ук ирекле рәвештә чыгып киткән гражданнарга яңа һөнәрләргә өйрәнү һәм эшкә урнашу чорына уртача хезмәт хакын саклау буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлектә:

1.2 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1986 елда читләштерү зонасыннан эвакуцияләнгән (шул исәптән ирекле рәвештә чыгып киткән) яисә 1986 елда һәм аннан соңгы елларда, балаларны, шул исәптән эвакуацияләү вакытында ана карынындагы (булган) балаларны да кертеп, күчерелгән (күчерелүче), шул исәптән ирекле рәвештә чыгып киткән гражданнар (1986 елның 30 июненнән соң күчерелү зонасына даими яшәү урынына күченгән гражданнарга, алар күрсәтелгән зонадан ирекле рәвештә яңа яшәү урынына күченгән очракта, «Чернобыль АЭСында һәлакәт аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарны социаль яклау турында» 1991 елның 15 маендагы 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының (алга таба – 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законы) 17 статьясында каралган социаль ярдәм чаралары, Чернобыль һәлакәте аркасында радиоактив пычранган башка зоналарда яшәү вакытын исәпкә алып, әлеге зонада яшәүгә бәйле нигезләрдә аларның пенсиягә чыгу хокукын алуы шарты белән бирелә. Бу очракта Чернобыль һәлакәте аркасында радиоактив пычрану дәрәҗәсе тагын да югарырак яисә шундый ук булган зонага ирекле рәвештә яңадан күченү 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясында каралган социаль ярдәм чараларын алу хокукын барлыкка китерми. 1994 елның 1 гыйнварыннан соң ирекле рәвештә (тиешле хакимият белән контрактлар, шартнамәләр төземичә) читләштерү, күчерелү зоналарына күченгән гражданнарга 1244-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 17 статьясында каралган социаль ярдәм чаралары бирелми);»;

өченче абзацта «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктның җиденче абзацында «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктта «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Законы» сүзләрен «Россия Федерациясе Законы» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Уртача хезмәт хакын саклау турында (саклаудан баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гариза җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр алына:

гражданинны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмә, яңа һөнәргә (белгечлеккә) укыту өчен юнәлтелү турында мәгълүматны үз эченә ала – Һөнәр һәм квалификация нигезендә яңа яшәү урынында беренче чиратта эшкә урнашу мөмкинлеге булмаганда яңа һөнәрләргә (белгечлекләргә) өйрәнү чорына

уртача хезмәт хакын саклау өчен (халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләрендә);

гражданинны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмә – яңа яшәү урынына килгәннән соң эшкә урнашу чорына уртача хезмәт хакын саклау өчен (халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләрендә);

хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында);

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган вәкаләтле оешма

хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

2.12 һәм 2.15 пунктларның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.1 пунктның 3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Уртача хезмәт хакы саклау буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедуралардан тора:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) уртача хезмәт хакы саклау буенча документлар җыелмасын кушып, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) уртача хезмәт хакы саклау турында (саклаудан баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү;

7) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.»;

3.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ала:

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләреннән гражданинны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмә, яңа һөнәргә (белгечлеккә) өйрәтү өчен юнәлтелү турында мәгълүматны үз эченә ала;

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләреннән билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмә;

Россия Федерациясе Пенсия фондыннан – хосусый шәхси счетның иминият номеры турында белешмәләр).

3.4.2. Үзәк бүлегендә уртача хезмәт хакын саклау турында (саклаудан баш тарту турында) карар кабул итү өчен зарури белешмәләр булмаганда, Үзәк бүлеге белгече, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә, түбәндәге белешмәләрне бирү турында электрон рәвештә үтенечләр җибәрә:

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесеннән гражданинны билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмә, яңа һөнәргә (белгечлеккә) өйрәтү өчен юнәлтелү турында мәгълүматны үз эченә ала;

халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениесеннән билгеләнгән тәртиптә эшсез дип тану турында белешмә;

Россия Федерациясе Пенсия фондына – хосусый шәхси счет буенча иминият номеры турында белешмәләр.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында үтенечләр, алынган белешмәләр.

3.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Үзәк белгече әлеге Регламентның 3.4.1 һәм 3.4.2 пунктчаларында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

4 бүлекнең 4.1 пунктындагы икенче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек)» сүзләрен төшереп калдырырга;

4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «1957 елда "Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга айлык акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында» 2012 елның 16 июлендәге 564 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.07.2015 № 456, 07.06.2016 № 317, 08.06.2017 № 351, 15.11.2017 № 804, 15.05.2018 № 368, 18.09.2018 № 886, 20.06.2019 № 486 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган 1957 елда "Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга айлык акчалата компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлекнең 1.5 пунктының алтынчы абзацында «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында:

2.4 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар (ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша гариза җибәрү зарурлыгы булмаган очракта) килгән көннән башлап биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча документлар сорату зарурлыгы булганда дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты гаризаны һәм документларны теркәгән көннән соң ун эш көненә кадәр озайтыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган»;

2.6 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча хезмәт алучының хосусый шәхси счетының иминият номеры турында белешмәләрне раслый торган документлар алына (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

Мөрәҗәгать итүче шушы пункттагы белешмәләрдән торучы документларны, шул исәптән, мөмкинлек булганда, электрон рәвештә, тапшырырга хокуклы.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Мөрәҗәгать итүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Үзәк бүлеге мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органнар, муниципаль хезмәтләрне күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле хакимиятләр һәм башкару-боеру вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы бүтән җирле үзидарә органнары (алга таба – җирле үзидарә органнары) яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган, дәүләт хезмәтен күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга салучы норматив хокукый актларда тапшырылуы күздә тотылмаган документларны тиешенчә федераль башкарма хакимият органнарыннан, бюджетныкы булмаган дәүләт фондлары органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан, шулай ук җирле үзидарә органнарыннан;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматлар тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза беренче мәртәбә тапшырылганнан соң дәүләт хезмәтен күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң дәүләт хезмәтен күрсәтү турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган һәм элегрәк тапшырылган документлар җыелмасына кертелмәгән гаризада һәм документларда хаталар булганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартудан соң документларның гамәлдә булу срогы беткәндә яисә мәгълүматлар үзгәргәндә;

дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда дәүләт хезмәте күрсәтүче вәкаләтле оешманың, дәүләт хезмәтен күрсәтә торган вәкаләтле оешма хезмәткәренең ялгыш яки хокукка каршы килә торган гамәлен (гамәл кылмавын) документаль раслаучы фактны (билгеләрне) ачыклаганда, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүче вәкаләтле оешма җитәкчесенең имзасы белән язмача рәвештә хәбәр ителә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә»;

2.12 һәм 2.15 пунктларның «Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив акт» графасында «РФ Президенты» сүзләрен «Россия Федерациясе Президенты» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлектә:

3.1 пунктның 3.1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) компенсация билгеләү буенча документлар җыелмасын кушып, гаризаны кабул итү һәм теркәү, яисә документларны кабул итүдән баш тарту;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү һәм кабул итү;

5) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) дәүләт хезмәтен күпфункцияле үзәкләрдә күрсәтү;

7) техник хатаны (язу, басма хатасын, грамматик яки арифметик хатаны) төзәтү.»;

3.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле 3.3.3 пунктча өстәргә:

«3.3.3. Мәгълүматлар алу, ведомствоара гарызнамәләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.3.3.1. Үзәкнең бүлек белгече хосусый шәхси счетның иминият номеры турында электрон формада мәгълүмат ала (Россия Федерациясе Пенсия фондында).

3.3.3.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә Россия Федерациясе Пенсия фондыннан хосусый шәхси иминият номеры турында белешмәләрне бирү турында гарызнамәләр җибәрә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документлар килгән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон рәвештә алынган белешмәләр, мәгълүматлар бирү турында гарызнамәләр.»;

3.4.1 пунктчада:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Үзәк белгече әлеге Регламентның 3.3.3 пунктчасында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә һәм мөрәҗәгать итүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:»;

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:


«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Документларны ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша сорату зарурлыгы булганда, – гарызнамәләргә җавап килгән вакыттан башлап ике эш көне эчендә, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көненнән соңга калмыйча.»;

4 бүлекнең 4.1 пунктындагы икенче абзацында «(алга таба – Идарә (бүлек)» сүзләрен төшереп калдырырга;

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга ай саен түләнә торган акчалата компенсация түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

## 1957 елда «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге авария һәм Тичә елгасына радиоактив калдыклар эләгү аркасында радиация тәэсиренә дучар булган гражданнарга ай саен түләнә торган акчалата компенсация түләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелеге буенча БЛОК-СХЕМА



Үзәк бүлеге белгече

Мөрәҗәгать итүчегә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карарны җиткерә, уңай карар булганда эш формалаштыра – 1 эш көне эчендә

→ Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү

Үзәк бүлеге белгече

Мөрәҗәгать итүчедән техник хатаны төзәтү турында гариза килгәндә, компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар проектын 1 эш көне эчендә үзгәртеп рәсмиләштерә

→ Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проекты

Үзәк бүлеге җитәкчесе

1 эш көне эчендә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын карый һәм

→ Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән, имзаланган

Үзәк бүлеге белгече

1 эш көне эчендә мөрәҗәгать итүчегә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә

→ Компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү".